СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

_____________ с. Верхний Услон № 43-579

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы
Контроль-хисап палатасына тышкы муниципаль финанс тикшерүен
гамәлгә ашыру буенча җирлекнең ревизия органнары вәкаләтләрен тапшыру турында

РФ Бюджет кодексын гамәлгә ашыру максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләренең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 7 декабрендәге 6-ФЗ номерлы Федераль закон, Югары Ослан муниципаль районы Уставы нигезендә, Югары Ослан муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары мөрәҗәгатьләрен исәпкә алып,

Югары Ослан муниципаль районы Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми, Югары Ослан, Введенский Бистәсе, Вахитов, Куралово, Килди, Карагуҗа, Канаш, Макыл, Мәйдан, Яңа Рус Мәмәтхуҗасы, Октябрьский, Соболевский, Бурнаш, Печище, Яр буе Морквашы, Түбән Ослан, Шылаңгы, Ямбулат авыл җирлекләренең тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру вәкаләтләрен кабул итәргә һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Контроль-хисап палатасына тапшырырга.
2. Югары Ослан муниципаль районы Советы аппаратына тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне гамәлдәге законнар нигезендә тапшыру турында килешүләр төзүне тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм регламент буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе урынбасары,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы урынбасары С.В. Осянин